Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

КАРАР № II-8

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 6 октябре

Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибен раслау хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р.Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2020 елның 6 октябрендәге
II-8 номерлы карары
белән расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр
төзү Тәртибе

1. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм “Балык Бистәсе муниципаль районы” (алга таба текст буенча – Район) муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең әлеге Тәртибе “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон) нигезендә эшләнде.

2. Район составына керүче аерым җирлекләрнең җирле үзидарә органнары Район җирле үзидарә органнары белән әлеге җирлекләр бюджетларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен аларга тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта Районның җирле үзидарә органнары Җирлек территориясендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрен “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча Районның җирле үзидарә органнарына аерым вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашыралар.

3. Районга җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру өчен Балык Бистәсе муниципаль район Советы Район составына керүче җирлекләр Советларына аңа җирлек вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә. Аерым вәкаләтләрне тапшыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләрнең инициаторлары булып Балык Бистәсе муниципаль районының җирлекләр Советлары да тора ала.

4. Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру мәсьәләләре Район Советы һәм җирлекләр Советлары утырышларында карала һәм карарлар рәвешендә рәсмиләштерелә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр турыдан-туры әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары арасында төзелә.

Күрсәтелгән килешүләр билгеле бер срокка төзелергә, аларның гамәлдә булуын туктату, шул исәптән вакытыннан алда туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләрне, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның әлеге өлештә күрсәтелгән еллык күләмен билгеләү тәртибен үз эченә алырга, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

6. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен зарури бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында бюджет законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен зарури чаралар күздә тотылган Район һәм җирлекләр бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрне формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Финанс средстволарын максатчан файдаланмаган очракта, алар җирлек бюджетына ун көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

7. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, түләүсез срокры файдалану шартнамәсе нигезендә муниципаль мөлкәт тапшырыла.

Түләүсез файдалану шартнамәсе срокры итеп һәм Килешүнең гамәлдә булу вакытына төзелә.

8. Бюджет процессын оештыру һәм җирлекләрнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең лицевой счетларын ачу буенча килешүләр нигезендә тапшырылган аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Районның җирле үзидарә органнары үз матди ресурсларын һәм финанс чараларын файдаланалар.

9. Вәкаләтләрен тапшырган җирлекнең җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны соратып ала.

10. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

- Якларның килешүе буенча;

- Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, берьяклы тәртиптә.

11. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Районның җирле үзидарә органы файдаланылмаган финанс чараларын һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди ресурсларны һәм мөлкәтне кире кайтара.

12. Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру яки килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда күздә тотылган башка тәртиптә каралырга тиеш.